СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июль, 2026 ел № 82

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2016 елның 08 августындагы 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 05 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2016 елның 08 августындагы 78 номерлы карары (16.10.2019 № 317, 27.10.2025 № 5, 12.12.2025 № 25 карарлары редакциясендә) белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы өстенлекләре» дип аталган 4.4 бүлегең түбәндәге эчтәлекле 29 абзац белән тулыландырырга:

«Биектау муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру кысаларында туристлык-рекреация кластерын үстерүгә һәм табигый ландшафтларның җәлеп итүчәнлеген арттыруга өстенлекле игътибар

бирелә. Бу юнәлештә тагын бер мөһим проект булып 16:16:220801:42 кадастр номерлы җир кишәрлегендә «Урманчы» заманча спорт ял базасы булдыру тора, бу территория икътисадын диверсификацияләүдә мөһим адым булачак. Әлеге проект дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр җәлеп итү механизмнары нигезендә гамәлгә ашырылачак, бу инфраструктураның сыйфатлы үсешен тәэмин итәргә һәм район халкы өчен яңа эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирәчәк. «Урманчы» ял базасын ачу, Биектау районына Татарстан Республикасында туристларны җәлеп итү буенча әйдәп баручы үзәкләрнең берсе статусын беркетеп, актив ял итү һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлекләрен сизелерлек киңәйтәчәк. Әлеге проектны гамәлгә ашыру өчен Красносельский авыл җирлеген территориаль планлаштыру документларын тиешенчә туры китерү эшләрен башкарырга кирәк булачак.»

2. 4 бүлектә, 4.5.1 таблицасын 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Советының 2026 елның
«30» июль 82 номерлы
карарына 1 нче кушымта

4.5.1 нче таблица

| **Инвестиция проекты исеме** | **Оешма - инвестиция проекты инициаторы исеме** | **Гамәлгә ашыру сроклары (инвестицияләр кертү)** | **Проект бәясе, млн. сум** | **Инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында төп капиталга инвестицияләр күләме, еллар буенча, млн. сум (НДСтан башка)** | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2016** | **2017** | **2018** | **2019** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** | **2024** | **2025** |
| 1200 баш савым сыерына сөт һәм ит җитештерү буенча терлекчелек комплексы төзү | «Бөреле» ЯАҖ | 2019-2020 ел | 250,0 | | | | 250,0 | | | | | | |
| «ПЗК» АҖ терлекчелек комплексының 3, 4 һәм 5 чиратын төзү юлы белән куян ите җитештерү куәтләрен киңәйтү | «Нәсел куян заводы» АҖ | 2016-2017 ел | 1947,0 | 578,0 | 1369,0 | | | | | | | | |
| Сөт үткәргечне алыштыру | «Правда» ААҖ | 2016 ел | 2,0 | 2,0 | | | | | | | | | |
| Ферма төзү | «Правда» ААҖ | 2017-2019 ел | 13,0 | | 3,0 | 4,0 | 6,0 | | | | | | |
| Ашлык киптерү җайланмасы, ашлык саклагыч | «Әсән» ААҖ | 2016 ел | 50,0 | 50,0 | | | | | | | | | |
| Сыер абзары (500 баш) | «Әсән» ААҖ | 2018 ел | 200,0 | | | 200,0 | | | | | | | |
| Азык оны җитештерү | «Азык оны заводы» Сәүдә йорты» ААҖ | 2024 ел | 80,0 | | | | | | | | | 80,0 | |
| Порошоклы буяу җитештерү | «Макситон» ААҖ | 2024ел | 220,0 | | | | | | | | | 220,0 | |
| Битумнар җитештерү | «Смарт Битум» ААҖ | 2024ел | 300,0 | | | | | | | | | 300,0 | |
| Электр бүлү һәм җайга салу | «Энергоспецинжиниринг» ААҖ | 2024ел | 177,0 | | | | | | | | | 177,0 | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| аппаратурасын җитештерү | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| **Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасын төзү** | | | | | | | | | | | | | |
| Урта Алат ав. | | 2016 ел | 9,3 | | | | | | | | | | |
| Макаровка ав. | | 2017 ел | 8,8 | | 8,8 | | | | | | | | |
| Березовка пос. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 ел | 10,0 | | | 10,0 | | | | | | | |
| Казаклар ав. | | 2018 ел | 9,3 | | | 9,3 | | | | | | | |
| Гәр ав. | | 2017 ел | 7,5 | | 7,5 | | | | | | | | |
| Калинино ав. | | 2017 ел | | | | | | | | | | | |
| **Балалар иҗат мәктәбе, мәдәният йортлары** | | | | | | | | | | | | | |
| Биектау ав. | | 2016-2017 ел | 380,0 (100,0 млн. 2015 елда үзләштерелде) | 100,0 | 180,0 | | | | | | | | |
| Биектау т/юл ст. пос. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2025 | 244,041 | | | | | | | | | | 244,041 |
| Әлдермеш ав. | | 2025 | 53,5 | | | | | | | | | | 53,5 |
| **Стадион төзелеше** | | | | | | | | | | | | | |
| Биектау ав. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2017 ел | | | | | | | | | | | |
| **Поликлиника төзелеше** | | | | | | | | | | | | | |
| Биектау т/юл ст. пос. | | 2017 ел | 100,0 | | 100,0 | | | | | | | | |
| Биектау ав. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2024 ел | 89,386 | | | | | | | | | 89,386 | |
| Өбрә ав. | | 2024ел | 8,655 | | | | | | | | | 8,655 | |
| Бикнарат ав. | | 2024ел | 8,655 | | | | | | | | | 8,655 | |
| Олы Көек ав. | | 2025ел | 8,655 | | | | | | | | | | 8,655 |
| Тат. Урматы ав. | | 2025ел | 8,655 | | | | | | | | | | 8,655 |
| **Ветеринария хезмәте өчен бина төзү** | | | | | | | | | | | | | |
| Әлдермеш ав. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2017 ел | | | | | | | | | | | |
| **Канализация чистарту корылмаларын төзү** | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Чернышевка ав. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2017 ел | 45,255 | 45,255 | | | | | | | | | |
| **МФЦ төзү (авыл клублары)** | | | | | | | | | | | | | |
| Ташлы Кавал ав. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2016 ел | 5,0 | 5,0 | | | | | | | | | |
| Дачный ав. | | 2017 ел | 5,0 | | 5,0 | | | | | | | | |
| Олы Битаман ав. | | 2016 ел | 12,7 | | 12,7 | | | | | | | | |
| Биектау ав. мәктәп төзү | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2024ел | 2317,0 | | | | | | | | | 2317,0 | |
| Шигали ав. мәктәп төзү | | 2024ел | 539,165 | | | | | | | | | 539,165 | |
| Чернышевка ав. балалар бакчасын төзү | | 2024ел | 437,872 | | | | | | | | | 437,872 | |
| Биектау т/юл ст. пос. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2025ел | 79,77 | | | | | | | | | | 79,77 |
| **Янгын сүндерү депосын төзү** | | | | | | | | | | | | | |
| Биектау т/юл ст. пос. | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | 2025ел | 54,990 | | | | | | | | | | 54,990 |
| **«Кызыл Тау» күпфункцияле спорт-савыктыру комплексын төзү** | | | | | | | | | | | | | |
| Красносельский АЖ | «Тимерхан» Финан корпорациясе» ААЖ | 2025-2029ел | 500,0 | | | | | | | | | | |
| **Теннис буенча Татарстан Республикасы җыелма командасы спортчылары өчен тренировка базасы** | | | | | | | | | | | | | |
| Урманчы пос. | «Татарстан Республикасы теннис федерациясе» РОО | 2025-2029ел | 500,0 | | | | | | | | | | |
| **16:16:220801:42 җир кишәрлегендә «Урманчы» спорт ял базасын булдыру** | | | | | | | | | | | | | |
| Урманчы пос. | Хосусый инвестор | 2027-2029ел | 150,0 | | | | | | | | | | |